Бүгенге санда:

Татарстан парламентаризмына 25 ел. 2 бит

# Дуслык

Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Чәршәмбе 27 май 2015 ел № 38 (10567)

**28 майга һава торышы:** аз болытлы һава, җил көньяк-көнчыгыштан 4-5 м/с; температура көндез +30°С, төнлә +22°С

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

*Абзац-информ*

### КОТЕЛЬНЯЛАР ҮЗГӘРЕШ КИЧЕРӘ

Нурлат җылылык челтәрләре 2016 елда үз карамакларындагы барлык 40 мини-котельняны да автоматлаштырып һәм диспетчерлаштырып бетерергә ниятли. Яңа проектлар булдыру, заманча җиһазлар сатып алу, белгечләр укыту кебек эшләрдән торган күчү чоры өч ел бара инде. Быел челтәр 10 мини-котельняда реконструкция үткәрергә ниятли. Моннан тыш, мини-котельняларда 5 яңа казан кую да планлаштырыла.

### ЭШМӘКӘРЛӘР БӘЙРӘМЕ

Кичә Нурлат эшмәкәрләре һөнәри бәйрәмнәрен билгеләп үттеләр. Рәсми мәгълүматлардан күренгәнчә, районда кече бизнес белән 2461 кеше шөгыльләнә. Ә һөнәри бәйрәмнәр календарендагы бу дата – чагыштырмача яңа әле, илебездә ул 2007 елдан бирле билгеләп үтелә.

### РАЙОН ДАНЫН АВЫЛНЫКЫЛАР ЯКЛЫЙ

Яңа Иглай урта мәктәбенең яшь юл хәрәкәте инспекторлары командасы район данын Яр Чаллыда уза торган "Имин тәгәрмәч" республика конкурсында яклый. 27-30 майга кадәр барачак ярышлар шәхси һәм команда зачетларында узачак.

### ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!

**"Дуслык" район газетасына язылу дәвам итә. Почтага һәм редакциянең реклама бүлегенә ашыгыгыз!**

## Ышанычны акларга да туры киләчәк



Лилия Мөбаракшина фотосы

САЙЛАУЧЫЛАР ҮЗ ФИКЕРЕН ЯШЕРЕН ТАВЫШ БИРҮ ЮЛЫ БЕЛӘН БЕЛДЕРДЕ

**Муниципаль сайлаулар алдыннан районда партия эчендәге алдан тавыш бирү эшчәнлеге кысаларында кандидатларның сайлап алучылар белән очрашулары кичә тәмамланды. Узган җомга көнне ул Нурлат шәһәрендә үтте.**

Бу көнне праймеризда 100 сайлап алучы каршына кандидат буларак катнашырга теләгән 30 кеше арасыннан 20сен сайлау бурычы куелган иде. Аудитория катнашучыларга яхшы ук таныш, арада моңарчы шәһәр советы депутаты йөген тартучылар да, иҗтимагый активлыклары яки һөнәри уңышлары белән танылган шәхесләр дә байтак күренде. Кандидатларның берничәсе үз программалары белән чыгыш та ясадылар. Тонны район һәм шәһәр башлыгы Равил Кузюров бирде.

–Битараф булмаска, халыкны ишетергә, алар фикеренә колак салырга,–диде Равил Әфраимович булачак депутат өчен иң кирәкле сыйфатны билгеләп.

Татьяна Фадеева, Алла Головенькина, Илфат Гәрәев, Евгений Савинов, Роман Чахмахчев төрле яшьтәге төрле тармак вәкилләре булсалар да, аларны бер сыйфат: активлык, халык мәнфәгатен алгы планга куеп эшләү теләге берләштерә иде. Катнашучылар моны билгеләми кала алмадылар.

– Праймеризлар, гомумән, районда бик эшлекле сөйләшү рәвешендә үтте. Халык актив булды, кандидатларга сораулар да яудырдылар, программаларына өстәмәләр дә керттерделәр. Очрашуга килүчеләр муниципалитет тормышына кагылышлы көндәлек сорауларны да күтәрделәр, – ди "Бердәм Россия" партиясенең Нурлат җирле бүлеге башкарма комитеты җитәкчесе Ралия Ханиева.

Сайлауларга әзерлекнең тәүге этабына халык битараф булмаган икән, үз кандидаты өчен тавыш бирергә дә бердәм килер, дигән ышанычка нигез бу. Ә сайлаучылар ышанычы – зур җаваплылык та.

Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА

ХУШ, МӘКТӘП!

## Чыгарылыш кичәсе бакчадан ук башлана

**Уку елы тәмамлану белән, ата-аналарга мәктәпләрдә, балалар бакчаларында чыгарылыш кичәләре уздыру мәшәкатьләре өстәлә.**

– Элек әти-әниләр баланың бакчадан мәктәпкә күчүен, башлангыч сыйныфларын тәмамлап югары сыйныфларга китүен белми дә калалар иде. Ә хәзер бу купшы вакыйгага әверелде. Кечкенә балалар – кечкенә проблемалар дисәләр дә, кызым бакчадан киткәндә 3 мең сум чыгым чыкты. Ә мәктәптә чыгарылыш тагын да кыйммәткәрәк төшәчәк. Бөтен ата-ана акча биргәч, мин генә кала алмыйм бит, - ди бер газета укучыбыз.

Ә шәһәрнең бер урта мәктәбендә башлангыч сыйныфларны тәмамлап, 5нчегә күчкән һәр баладан укытучыларына 500әр сум акча җыю хәбәре дә килеп иреште. "500 сум укытучыга гына, моннан тыш, кафесы, экскурсиягә барса – транспорты, чыгарылыш альбомы, күлмәк, чәчәк бәйләме..."

Дөрес, бу уңайдан башка фикерләрне дә ишетергә туры килде. Мисал өчен, шәһәрнең 3нче урта мәктәбендә сыйныф җитәкчесе чыгарылыш кичәсе уңаеннан акча җыюларга бөтенләй каршы килгән. Чыгарылыш вакыйгасын укучылар белән экскурсиядә билгеләп үтәргә тәкъдим иткән.

– Әгәр әти-әниләр балалары өчен бәйрәм оештырырга телиләр икән – үткәрсеннәр, - ди әлеге ситуациягә аңлатма биреп район мәгариф бүлеге җитәкчесе Линар Маняпов. – Мондый кичәләр барлык әти-әниләрнең теләкләрен исәпкә алып кына үткәрелә ала. Ә укытучылар, тәрбиячеләргә бүләк бирү турында сүз дә була алмый. ТР мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттаховның узган елның 7 сентябрендәге акча җыюларны тыюга багышланган хаты турында даими кабатлап торабыз. Шуңа да әти-әниләрнең замана модасына кушылып, бүләк өчен акча җыймауларын сорар идем. Моннан тыш, чыгарылышлар өчен оештырылучы экскурсияләр мәсьәләсенә тукталып узасым килә. 22 майга кадәр әлеге сәфәрләр рөхсәт ителсә, хәзер укучыларга чит шәһәрләргә экскурсияләргә бару тыелды. Бу туроператорларның документларын тикшерү белән бәйле. Сүз дә юк, алар акча эшләү максатыннан төрле экскурсияләр тәкъдим итә, ә балаларның иминлеге өчен җаваплылык безнең өстә кала.

Район мәгариф идарәсендә хуҗалык ихтыяҗларына средстволар җыю буенча да төгәл аңлатма бирделәр. Иганәчелек ярдәменә беркем дә каршы түгел. Сыйныфларда ремонт ясау теләге булганнар средстволарны мәгариф учреждениесенең исәп-хисап счетына күчерергә тиеш. Ә акчаны ата-аналар комитетына кулдан бирү ярамый.

Сүз дә юк, чыгарылыш кичәләрен әти-әниләр оештыра. Әмма бәйрәм баланың күңеленә матур вакыйга булып кереп калсын өчен купшы бүләкләр, чамадан тыш акча сарыф итүләр һич мәҗбүри түгел. Иң мөһиме, чара ихлас, кызыклы булып узсын һәм мәкальдәгечә, юрганыңа карап аяк сузу хәерле.

*Хөрмәтле газета укучыларыбыз! Сезнең балалар укыган мәктәпләрдә, балалар бакчаларында чыгарылыш кичәләре ничек оештырыла? Без сезне сөйләшүгә чакырабыз. Үз фикерләрегезне nurlat-tat.ru сайтына юллый аласыз.*

Зилия ӘКСАНОВА

# КӨН АРТЫННАН КӨН

## Моңсу, әмма тантаналы бәйрәм



МӘКТӘП БЕЛӘН ХУШЛАШУ БИЛГЕСЕ – "СОҢГЫ КЫҢГЫРАУ" ЧЫҢЛЫЙ

**Узган атнада районның 330 чыгарылышы өчен соңгы кыңгырау чыңлады.**

Гимназия белән хушлашкан 37 унберенче исә кызыклы фактны ачыклаган: унбер ел эчендә кыңгырау аларны 4,500 тапкыр дәрескә чакырып яңгыраган икән.

Мәктәп белән хушлашу бераз моңсурак булса да, егет-кызларның кәефләре бәйрәмчә иде.

– Бераз дулкынландырса да, олы тормышка юл алуым белән мин бик бәхетле, – ди Роман Мордвинов. Гимназиянең быелгы чыгарылышы иҗади, спорт сөюче һәм хәрби-патриотик юнәлешне яратучы укучыларга бай булган. Араларында спорт төрләре, парашют спорты буенча разрядларга ия булучылар да бар иде. Мәктәп җитәкчелеге бер төркем активистларны тантаналы линейкада Мактау грамоталары белән дә билгеләп үтте. Гимназия чыгарылышларының тормыштагы әлеге зур шатлыгын әти-әниләре, якыннары һәм укытучылары белән бергә бәйрәм итте. Гимназия чыгарылышларының тормыштагы әлеге зур шатлыгын әти-әниләре, якыннары һәм укытучылары белән беррәттән, район башлыгы Равил Кузюров та уртаклашты.

– Бүген бик дулкынландыргыч көн – балаларны олы тормыш юлына озатабыз, – диде район башлыгы. – 11 ел бер көн кебек сизелми дә узып киткәндер, мөгаен. Чыгарылышларның көр кәефен күреп сөенәм. Сезгә имтиханнарны уңышлы тапшырып, үзегез теләгән вузларга укырга кереп, тормышта үз урыныгызны табуыгызны телим. Алга таба районга югары квалификацияле белгечләр булып кайтуыгызга өмет итәм.

Шунда ук район башлыгы белем бирү учреждениесенә акчалата сертификат та тапшырды.

Гимназистларга ТР мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттаховның котлау сүзләрен министрлыкның балаларга өстәмә белем һәм тәрбия бирү бүлеге әйдәп баручы киңәшчесе Семен Федоров җиткерде.

Чарада әти-әниләр исеменнән чыгыш ясаган ТР ДОСААФының Нурлат районы бүлеге җитәкчесе Радик Гыйниятуллин өчен соңгы кыңгырау бәйрәме аерата үзенчәлекле икән.

– Шәхсән миңа бүгенге бәйрәмдә икеләтә моңсу, – диде ул. – Беренчедән, олы улым мәктәпне тәмамлый, икенчедән ДОСААФ хезмәткәре буларак, әлеге чыгарылышлар белән без батырлык мәктәбен үттек. Спортчы-парашютчылар, кадетлар сыйныфы булганга күрә, һәрвакыт бергә булдык.

Чараның рәсми өлешендә чыгарылышларга үз теләкләрен район мәгариф бүлеге җитәкчесе Линар Маняпов, башка рәсми затлар һәм башлангыч сыйныф укучылары җиткерде.

"Соңгы кыңгырау" бәйрәме кеше тормышына бер генә тапкыр килүче гаять зур вакыйга булса да, чыгарылышлар күңел ачарга ашыкмады. Мисал өчен, шәһәрнең 2нче урта мәктәбенең 31 укучысы, традицияне дәвам итеп, шәһәр паркындагы Чыгарылышлар аллеясына миләш агачлары утырттылар. Аллеяга исә әлеге мәктәпнең 2014 елгы чыгарылышлары нигез салган иде.

Зилия ӘКСАНОВА

ХУШ, МӘКТӘП!

## Шәкертләрне "Соңгы сыбызгы" озатты

**Балалар-үсмерләр спорт мәктәбе дә үзенең 50 чыгарылышы белән хушлашты: алар арасында күпчелекне футболчылар, волейболчылар, көрәшчеләр тәшкил итте.**

Быелгы чыгарылыш кичәсен мәктәп җитәкчелеге спортчыларга ятышлы итеп "Соңгы сыбызгы бәйрәме" исеме астында үткәрде. Мәктәп директоры Фәнил Гайнуллин яшь спортчыларга теләкләрен җиткергәннән соң, ДЮСШда тулы курс буенча, ягъни – сигез ел дәвамында балаларының шөгылен хуплаган, мәктәпнең тормышында актив катнашкан ата-аналарга рәхмәтен җиткерде.

– Бу ел аерата уңышлы булды, безнең спорт мәктәбе республикадагы 150гә якын ДЮСШ рейтингында унҗиденче урынга күтәрелде, бездән алдагы позицияләрдә бары тик Казан, Яр Чаллы мәктәпләре генә, һәм монда, һичшиксез, ата-аналарның роле дә бик зур, – диде ул. Аннан ДЮСШны тәмамлаучыларга таныклыклар тапшырылды. Ә биш укучы спорт мастерлыгына кандидат кенәгәсе һәм значогына да ия булды, моннан тыш, I өлкәннәр разряды нормаларын үтәүчеләр дә бар иде.

Бәйрәм ДЮСШның төрле секцияләрендә шөгыльләнүче яшь спортчыларның күрсәтмә чыгышлары, иҗади номерлар белән үрелеп барды. Чыгарылыш кичәсе исә символик "соңгы сыбызгы" тавышын яңгырату белән төгәлләнде.

Спорт мәктәбе ел саен 50ләп шәкертен олы тормыш юлына озата тора, ә ДЮСШда шөгыльләнүчеләр саны елдан-ел арта. Мисал өчен, бүгенге көндә мәктәпнең үзендә һәм филиалларында 700дән артык бала берничә спорт төре белән шөгыльләнә. Киләсе елга исә шәкертләр санын меңгә җиткермәкчеләр.

Илназ МӨБАРӘКШИН



ТРЕНЕР ВЯЧЕСЛАВ ЛОБОВ МӘКТӘП БЕЛӘН ХУШЛАШУЧЫ ВОЛЕЙБОЛЧЫ КЫЗЛАРЫНА МАХСУС БҮЛӘКЛӘР ДӘ АЛЫП КИЛГӘН ИДЕ

КӨН КАДАГЫНДА

## Коену да, урманнар да контрольгә алына

**Җиһазландырылмаган урында, исерек көе коену, ата-аналарның игътибары җитенкерәмәү – олылар һәм балаларның җәйге чорда суда батып үлүләренең төп сәбәпләре.**

Район аша берничә елга ага, әмма, кызганычка каршы, санкцияләнгән коену урыннарының бездә булганы юк. Суларда кешеләрнең иминлеген тәэмин итү һәм коену сезонында аларның үлеменә юл куймау мәсьәләләре узган атнада республиканың Гадәттән тыш хәлләр комиссиясендә төп тема булды. Татарстанда елга-күлләр күп булганлыктан, шулай ук ел саен актив ял итү өчен сулыкларны сайлаучы кешеләрнең үлем очракларының артуы сәбәпле, сулыкларда кешеләрнең иминлеге мәсьәләсе республика өчен аерата әһәмияткә ия.

– Кызганычка каршы, сулыкларда кешеләр үлү очраклары юл-транспорт һәлакәтләре һәм янгыннардан соң өченче урында тора, – диде Татарстанның кече суднолар буенча баш дәүләт инспекторы урынбасары Регина Гаязова. Шунда коену сезонында җиһазландырылган урыннарда кешеләрнең үлеме теркәлмәгәнлеге дә әйтелде. Бәлкем, бездә дә тиешле коткару чаралары белән җиһазландырылган пляжлар булса, сулыкларда кешеләр үлү куркынычы кимер иде. Әмма әлегә эссе көннәр килү белән нурлатлылар Чирмешәнгә юл тота, үзләренә ошаган урында коена, һәм моның никадәр куркыныч китерү ихтималлыгын белми дә. "Коенырга ярамый" дигән аншлаглар булуга да карамастан, барыбер суга керәбез. Шуңа да, район башкарма комитеты җитәкчесе Әсхәт Габдуллин видеокиңәшмәдән соң үткән район КЧСы утырышында әйтүенчә, сулыкларда иминлекне тәэмин итү өчен сәламәт яшәү рәвешен пропагандаларга, халык арасында санкцияләнмәгән урыннарда коенырга ярамаганлыгы турында профилактик эш алып барырга кирәк. Хәер, бераз сөендерерлек хәбәр дә бар: җәйге каникулларын сәламәтләндерү лагерьларында үткәрәчәк балалар өчен коену урыннары җиһазланачак.

– Җәйге чорда районда өч лагерь эшләячәк – "Заречный", "Нурсан", "Чияле Алан", 22 көндезге лагерь, 3 ял һәм хезмәт лагере, 2 палаткалы лагерь да булачак. Өч лагерьда да су коену өчен бассейннар, йөзү буенча инструкторлар бар, – диде Әсхәт Касыймович.

Җәйге чорда су коенудан тыш, КЧСта тагы берничә мәсьәлә каралды. Нурлат урманчылыгында янгынга каршы чорга әзерлек турында аның җитәкчесе-урманчы Рөстәм Галиев сөйләде. Гомуми мәйданы 83770 гектар тәшкил иткән Нурлат урманчылыгында 100 километр минеральләшкән полоса булдырылган, 119 километры яңартылган. Баш урманчы әйтүенчә, урман янгыннарын сүндерү планы эшләнгән, ылыслы һәм яшь агачлар контрольгә алынган.

Нурлат гарнизоны начальнигы Илһам Курамшин бүгенге хәл һәм янгыннар чыккан очракта килеп туу ихтималы булган рискларны йомшарту буенча беренчел чаралар турында мәгълүмат җиткерде. Ул 2010-2014 елларда районның урман фондында янгыннарга юл куелмавын да билгеләп үтте.

– Синоптиклар фаразы буенча, язгы-җәйге чорда янгын куркынычы уртача дип бәяләнә, – диде ул. – Коры үлән, камыш авылларда гына түгел, шәһәрдә дә янгынның тиз таралуына китерергә мөмкин. Чөнки Нурлат тирәсендә 7 бакчачылык ширкәте бар, шуларның 70 проценты – ташландык. Ел башыннан аларда 20 тапкыр ут чыкты.

Янгын часте начальнигы урман янгыннарына аерата дучар булган торак пунктларны да атады, алар җидәү. Һәм шуларның кайберләрендә хәбәр салу системалары эшләми икән. Мисал өчен, Единениедә аны, шәхси йортка тоташтырылганлыктан, электр челтәреннән үзләре үк өзгәннәр. Янгын куркынычы чоры уңаеннан мәгълүматны күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге начальнигы Николай Захаров та тулыландырды. Ул пирслар, гидрантлар, су башняларына кагылды. Район башлыгы урынбасары Флюра Ногманова әйтүенчә, бу тема ябылмаган әле, һәм хәбәр салу системаларын, янгын гидрантларын тикшерү дәвам итәчәк.

Сирень СӘМӘРХАНОВА

ҖИҢҮ СОЛДАТЛАРЫ

##ҺӘР ГАИЛӘНЕҢ ҮЗ БАТЫРЫ



**Минемчә, һәр гаиләдә легендар фронтовиклар турында хатирә буыннан-буынга күчә бара.**

Минем карт бабам Нургата Абдуллин моннан 100 ел элек, 1915 елда крестьян гаиләсендә туган. Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтка китә. Ә өйдә тормыш иптәше белән бергә кечкенә балалары Әнәс белән Рөстәм кала. Карт бабай сугышның барлык җирләрендә диярлек була. Танк взводы командиры булып хезмәт итә. Көньяк-Көнбатыш, Ленинград һәм Украина фронтларында сугыша. Берничә тапкыр яралана. Җилкәсендәге мина ярчыгы аңа гомер буена дәһшәтле сугыш турында исенә төшереп тора. Сугыштан соң бабам тагын 50 ел яшәгән. Карт әбием белән бергәләп 7 бала үстереп тәрбияләгәннәр. Ул еш кына фронтовикларның авыр көндәлек тормышлары турында искә төшерде. Кайвакыт сөйләгәндә туктап калып, күз яшьләрен сөртә дә, аннан тагын хәтер яңарта торган булган. Аңа тормышның төрле чорын күрергә насыйп була. Кыюлыгы өчен "Батырлык өчен", "Ленинград оборонасы өчен", "1941-45 еллардагы Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен" медальләренә, инде тыныч тормышта Ватан сугышы орденына ия була. Аның парад кителен юбилей медальләре бизәп тора. Инде карт бабамның арабыздан китүенә 20 ел узса да, аның турындагы матур истәлекләр безнең күңелләрдә яши әле.

**Ралиф КАШАПОВ, 2нче мәктәп**

---

**Сәкинә Хәйруллина**

Ветераннар китә. Кайтмаска дип.
Бурычлары Җирдә үтәлгән.
Шушы гаярь буын сугыш үтеп
Җиңү әләмнәрен күтәргән.

Кул сузымы гына калды юкса
Шанлы бәйрәм көнен күрергә.
Хәтерләрдә кабат ул көннәрнең
Җанлы сурәтләрен үрергә.

Орден-медальләрнең чыңы тынды,
Бакыйлыкка күчте хыяллар.
Солдат һәйкәленә венокларны
Тик аларсыз гына куярлар.

Ветераннар китә. Чор хәтере
Өзгәләнә, сызлый, уйлана.
Киткәннәрнең йөрәк ялкыныдай
Һәйкәл итәгендә ут яна.

---

"ФРОНТТАН ХАТ" ПРОЕКТЫ

# Бер хат тарихы

**Безнең гаиләдә кадерләп саклана торган ядкәрләр бар. Алар – минем әбиемнән калган йөзек, беләзек, чулпылар, бабамның ордены, аның сугыш вакытында язган бердәнбер хаты һәм фотолар. Мин әлеге хатның тарихы һәм фотосурәтләрдәге ерак бабаларымның язмышы белән кызыксына башладым.**

Бабам Вахитның сөйләве буенча, аның бабасы Вәлиәхмәт һәм аның энесе Салих бабай Шәмсуаровлар Нурлат районының иң гүзәл, иң матур табигатьле Үрнәк авылына нигез салучыларның берсе булалар. Вәлиәхмәт бабамның ике улы булган. Аларның берсе 1910нчы елда туган, минем бабамның этисе - Вәлиәхмәтов Исмәгыйль Вәлиәхмәт улы, икенчесе 1916 нчы елда туган Вәлиәхмәтов Юныс Вәлиәхмәт улы. Икесе дә сугышның беренче көннәрендә үк фронтка киткәннәр. 1941нче елның ноябрь аенда үк бабам бик каты яралана, ләкин госпитальдән соң тагын фронтка китә. 1943 нче елда Казан шәһәренең танк училищесында офицерларны әзерләү курсларында белем ала. Әлеге хат нәкъ менә шул вакытта язылган була. Хаттан бер өзек:

*"Хәят, сиңа мин үземнең исәнлегемне тәгаенлим. Алгарак сезнең исән-сау һәм шат яшәвегезне теләп бик сагынып, бик саргаеп бик күпдин күп сәлам... Сәлам соңында берничә сүз, үзем мин исән-сау гына торам, һәм сезне дә исәнлектәдер диеп беләм. Мин сезгә хатлар салган идем һәм үземнең исән икәнлегем хакында язган идем. Мин хәзер Казанда 1943нче елның 1 мартыннан бирле. Бәлки, сез ул хакта ишеткәнсездер. Мин Гайшәбикәне күреп сөйләшкән идем. Шулкадәр сагындым инде, һәм кайгырдым да. Чөнки Юнысның үлүе хакында белдем, бик кайгырдым. Безнең өчен бу бик зур югалту инде. Көннәрнең һәм төннәрнең ничек үткәнлеген белгән юк. Бер көн дә ялгызым торасым килми. Минем сездән шул үтенеч, әткәй белән бергә Вахитны да алып минем янга килеп чыга алмассызмы. Сезне бер түйганчы күреп сөйләшәсем килә. Колхоздан ат алыгыз да килеп чыгыгыз. Мин өйгә кайтып килергә сорап карадым, ләкин җибәрмиләр.*

*Соңгы сүз дип тиз көн эчендә килеп чыгуыгызны үтенәмен. Мин бу хатны сезне минем янга җибәрсен өчен колхоз рәисенә дә яздым. Адресымны да җибәрәм".*

Авыр сугыш юлларында бик күп чакрымнарны узарга туры килә бабама. Ул 2нче Украина фронтының 6нчы танк армиясендә танк взводы командиры була. 1944нче елның 19-20нче декабрендә Чехословакиянең Туравце шәһәрен азат иткәндә көчле ут астында, дошманның оборонасын кисеп үтеп һөҗүмгә күчә. Кызганычка каршы, шул сугышта бабам үзе һәм аның взводы һәлак була. Бу вакытта Бөек Җиңүгә нибары 140 көн калган була... Бабам I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә. Бу кадерле ядкәр безнең гаиләдә саклана.

Оборона Министрлыгының үзәк архивы базасындагы мәгълүматларга караганда, Исмәгыйль бабам Чехословакиянең Гоковце авылында күмелгән. Ләкин 1946нчы елда сугыш тәмамланганнан соң бик күп каберләрне эксгумацияләп, солдатларны зуррак шәһәрләргә мемориалларда җирләгәннәр. Һәм менә шунда җепләр өзелә дә инде. Бүгенге көндә мин Словакиянең урыс телендә аралашаучы эзтабарлары белән элемтәдә торам. Һәм бабамның җәсәде күмелгән урынны табармын дип ышанам.

Исмәгыйль бабамның энесе Юныс абый Көнбатыш фронтның 1104 укчы полкында батальон командирының сәясәт эшләре буенча урынбасары була. Хәрби дәрәҗәсе – өлкән лейтенант. Аны бүләкләү турындагы приказда мондый юллар бар:

"1942 нче елның 4 августында Тверь өлкәсенең Зубцово районы Губинка авылы янындагы сугыш вакытында политрук Вәлиәхмәтов Юныс Вәлиәхмәт улы алдынгы сафларда бара иде. Һөҗүм вакытында кинәт безнең пулемет тынып калды, фашистлар бу мизгелдән файдаланып бер төркемгә җыелышып контратакага әзерләнә башладылар, автомат һәм пулеметтан атарга тотындылар. Иптәш Вәлиәхмәтов ут яңгыры астында шуышып, пулемет астына барып ятты, ул югалып калмыйча, тиз арада дошманны утка тотты. Шул арада 15 немецны юк итте. Бу пехотаның алга таба хәрәкәтләнүенә бик зур ярдәм булды."

Әлеге сугышта Юныс абый каты яралана. Госпитальдә аңа Кызыл Йолдыз ордены тапшыралар. Ә сугыш дәвам итә...

1943нче елның 12 мартында Смоленск өлкәсенең Вяземский районы Семово авылы янындагы сугышта абыебыз һәлак була. Юныс абыйның каберен ачыклау буенча да эш алып барам. Смоленск өлкәсенең Вяземский районы эзтабарлар отряды белән элемтәгә кердем.

Кызганычка каршы, бу авыл хәзерге вакытта юк инде. Ә аның янәшәсендә Семово сазлыгы дигән урыннар бар. Әнә шунда бик зур сугышлар булган. Бүгенге көндә бу урында, куркыныч булу сәбәпле, эзләнү эшләре алып барылмый диярлек. Юныс абыебызның исемен мәңгеләштерү өчен эзтабарлар тәкъдиме белән без Смоленск өлкәсенең хәрби комиссарына гариза яздык. Бүгенге көндә җавап көтәбез.

Безнең бабаларыбызның каберләрен табып, аларга туган җир туфрагын бик тә алып барасыбыз килгән иде. Бу минем бабам Вахитның да безгә әйтеп калдырган үтенече иде. Кызганычка каршы, бу батырларның каберләре генә дә юк.

**Алсу ВӘЛИӘХМӘТОВА, Нурлат гимназиясенең 8 Б сыйныфы укучысы.**

---

СУГЫШ ЧОРЫ БАЛАЛАРЫ

# Колхоз кызы Пелагея

**Тиздән 92 яшен тутырачак Пелагея Гавритухинаның катлаулы язмыш сәхифәләрен тулысынча күз алдына китерү өчен сәгатьләр генә түгел, көннәр буена сөйләшеп утыру кирәктер, мөгаен. Ул гомер юлларын барлаган арада, күңелдән бу әбекәйнең җыйнак кына гәүдәсе әлеге сынауларга ничек чыдады икән, дигән уй китмәде.**

Пелагея Самара өлкәсенең Шламка авылында 11 балалы гаиләдә дөньяга килә. Әмма балаларның барысы да гомерле булмый, әтиләре беренче көннәреннән үк сугышка киткәндә, әниләре 6 бала белән кала, бер атнадан исә төпчекләре Лиза дөньяга килә.

- Әниебезне бала табарга төнлә белән басу каравыллаганда алып киттеләр. Аның урынына исә мине бастырып калдырдылар. Әниебез баладан соң үзе дә өзлегеп калды, - дип исенә төшерә Пелагея Терентьевна. - 1941нче елда ук әтиебезнең Вязьма янындагы авыр сугышларда хәбәрсез югалды, дигән кәгазен генә алдык. Әниебезгә берсеннән-берсе кечерәк балаларын үстерү бик кыен булды. Авыр хезмәт өстенә займнар белән дә аптыраталар. Хәтерлим әле, бурычыгыз бар дип, йортыбыздагы соңгы сарыгыбызны алып чыгып киттеләр. Сеңелләрем Анюта белән Лиза авыл читендәге күпергә кадәр: "Сарыгыбызны кире бирегез. Ул булмагач, әниебез безгә җылы оекбашлар бәйли алмаячак бит", - дип елап йөгерделәр.

Сугыш башланганда 17 яшендә булган Пелагея гаиләдә иң өлкәне, бар да кыз балалар. Шуңа да бөтен авыр хезмәт аның җилкәсенә төшә.

- 6 яшемдә сыер сава идем инде. Колхоз эшенә 10–11 яшьтән йөри башладым. Шаяртып "колхоз кызы" дип йөртәләр иде үземне, - дип сүзен дәвам итә тыл ветераны. – Печән чапканда рәт белән тезелешеп басарга кирәк, мине исә буем кечкенә булганга иң артка бастыралар. Әмма бер дә калышмадым, башкалар белән бертигез эшләдем. Ниләр генә эшләргә туры килмәде инде: чәчтек тә, урдык та, берара хәтта ат караучы да булып эшләргә туры килде.

Аз булса да акчасы булыр, гаиләгә ярдәме тияр дип 18 яше тулу белән Нурлатка почта бүлегенә сортировщица булып эшкә урнаша кыз. Беренче хезмәт хакына тигән икмәкне күтәреп өенә, сеңелләре янына кайтуын әле дә хәтерли әле.

- Бер пот ипине капчык белән җилкәмә күтәрдем дә ашыга-ашыга кайтам. Түбән Нурлат хатыннары очрап, бик каты тиргәделәр үземне. Аннан Шламкага кадәр озатып куйдылар. Ә икмәк гаиләбез өчен зур бәйрәм булган иде.

Сугыш тәмамланганда, әниләре дә үлеп китә һәм балаларның кечкенәләре тулысы белән Пелагея канаты астында кала. Сугыштан соң кияүгә чыккач та аларны үзеннән калдырмый. Моннан тыш, тормыш иптәшенең туганнары да Гавритухиннар гаиләсендә җылылык таба. Хезмәт белән үскән Пелагея Терентьевна исә сынатмый: әзерләүләр конторасында эшли, тырыш хезмәте һәм активлыгы өчен шәһәр Советына депутат итеп тә сайлана, бик күп бүләкләргә лаек була. Тормыш иптәше белән 4 бала тәрбияләп үстерәләр.

- Безнең әни бик уңган, гомере буена үзе тегеп киендерде, бәйләде, – диләр улы Владимир белән килене Галина әниләре турында. – Хәзер дә фатирында тулы тәртип тота, кибеткә дә үзе чыгып керә әле, - диләр.

Инде тормыш иптәшен, ике баласын, сеңелләренең күбесен җирләгән Пелагея Терентьевна.


Автор фотосы

- Ходай миңа озын гомерне әти-әнием, якыннарым өчен дә биргәндер, мөгаен, - ди үзе.

Озын гомерле булуының тагы бер сере исә башкаларны кайгыртып, игелек күрсәтеп яшәвендә түгел микән әле?

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

